СОВЕТ АЛБАЙСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная, д.28, с. Албай,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422176

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АЛБАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
узәк ур., 28 нче йорт, Албай авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422176

тел.(факс): (85563) 3-05-08; e-mail: Alb.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

РЕШЕНИЕ
№ 7-7

КАРАР
03 март 2016 ел.

Кабул ителгән карарны теркәү турында
2016 елның 28 февралендә референдумда

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьяларына, Татарстан Республикасы Законының 18 статьясына ярашлы 24.04.2004 No 23-ТРЗ Җирле референдум турында, 2016 елның 28 февралендә референдум нәтиҗәләре нигезендә:
«2016 елда Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Албай авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 һәм 2 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында һәм сугыш хәрәкәтләрендә катнашучыларның тол хатыннарыннан, күп балалы гаиләләрдән, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, гражданнардан тыш, 200 сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы, Россия армиясе сафларына срочная хезмәткә чакырылган, һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү:

Торак пунктта яшәүчеләрнең күпләп ял итү өчен шартлар тудыру һәм халыкның күпләп ял итү урыннарын төзекләндерүне оештыру, шул исәптән гражданнарның гомуми файдаланудагы су объектларына һәм аларның яр буйларына ирекле керүен тәэмин итү:
Албай, Зур Арташ, Югары Арняш, жылы сазлык авылларында 8 (сигез) чишмә ремонтланган-52,0 мең сум.

«ӘЙЕ» «ЮК»

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Албай авыл жирлеге Советы:

1.Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы территориаль сайлау комиссиясенең «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы « Албай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә җирле референдум нәтиҗәләре турында»2016 елның 29 февралендәге 30 номерлы карарын теркәү.

2.Гражданнарның үзара салым акчаларын куллану юнәлешләрен һәм күләмнәрен кушымта буенча билгеләргә.

3.Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында, Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә mamadysh.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми порталы (pravo.tatarstan.ru).

Мамадыш муниципаль районы
Албай авыл жирлеге Советы Башлыгы / И. П. Крешков/

КУШЫМТА
Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Чалбас авыл җирлеге Советының 2016 елның 03 мартындагы 7-7 номерлы карарына

## Гражданнарның үзара салым акчаларын сарыф итү юнәлешләре һәм күләме

| N п/п | Җирле әһәмияттәге мәсьәләнең атамасы | Җирле әһәмияттәге мәсьәләнең атамасы | Чараларны гамәлгә ашыруга акча күләме, мең сум |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 2 | 4 |
| 1. | Торак пунктта яшәүчеләрнең күпләп ял итү өчен шартлар тудыру һәм халыкның күпләп ял итү урыннарын төзекләндерүне оештыру, шул исәптән гражданнарның гомуми файдаланудагы су объектларына һәм аларның яр буйларына иректә керүен тәэмин итү; | Торак пунктта яшәүчеләрнең күпләп ял итү өчен шартлар тудыру һәм халыкның күпләп ял итү урыннарын төзекләндерүне оештыру, шул исәптән гражданнарның гомуми файдаланудагы су объектларына һәм аларның яр буйларына иректә керүен тәэмин итү; | 52,0 |
| Барлыгы | | | 52,0 |